МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.11.2019. г.Казань № 984

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 4 декабрендә 5908 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
12.11.2019 № 984 боерыгы белән
расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 03 июлендәге 448 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 15.05.2018 №366, 18.09.2018 №886, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Акланган гражданнарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзенә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Акланган гражданнарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында күрсәтелде.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):»;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 п.).»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Акланган гражданнарга телефон урнаштыруга чыгымнарны кайтаруны билгеләү (алга таба – чыгымнарны кайтаруны билгеләү) | 6 статья, 3 абз., 63-ТРЗ номерлы закон, Нигезләмәнең 8.1 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 8.2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән бащ тарту) турында карар | Нигезләмәнең 8.3 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт | Чыгымнарны каплауны билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гариза җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла. | Нигезләмәнең 8.3 п. |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү чыгымнарны каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның туры исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Чыгымнарны каплауны билгеләү турында гариза (гариза бирүче тарафыннан кредит оешмасында ачылган почта адресын яисә счет реквизитларын күрсәтеп) (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән), түбәндәгеләрне теркәп: -<br>затның акланган гражданнар категориясенә каравын раслый торган документ күчермәсен;<br>телефон урнаштыру буенча күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләү турында документ күчермәсен;<br>телефон урнаштыру өчен чыгымнарны каплауны билгеләү буенча гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылган очракта, – ышанычнамә күчермәсен.<br>Документларның күчермәләре нотариус тарафыннан яисә орган (документның чын нөсхәсен бирүче оешма, учреждение) тарафыннан таныкланмаган очракта, алар чын нөсхәләре белән бергә тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан таныклана.<br>Акланган гражданнар, аларның законлы вәкилләре яисә ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспорт (аны алмаштыра торган документ) күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан | Нигезләмәнең 8.2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза белән документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер нөсхәдә тапшырыла | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча хезмәттән файдаланучының хосусый шәхси счеты иминият номеры турында | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | белешмәләрне раслый торган документлар алына (Россия Федерациясе Пенсия фондында).<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар | |

| | | |
|---|---|---|
| | карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки-мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасың яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел. | Россия Федерациясе Президентының |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә | 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 пункты<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$, $21^2$ статьялары; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Чыгымнарны каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) чыгымнарны кайтаруны билгеләү өчен теркәлгән документлар пакеты белән гаризаны кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны төзәтү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Үзәкнең бүлек белгече хосусый шәхси счетның иминият номеры турында электрон формада мәгълүмат ала (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Чыгымнарны кайтаруны билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси иминият номеры турында белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.4.1 пунктның икенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.7. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны

(андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктта «хезмәткәр» сүзен «учреждение белгече» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Акланган гражданнарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Акланган гражданнарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында

БЕЛЕШМӘЛӘР

1.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

1.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган затларны җирләүгә чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 гыйнварындагы 29 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.11.2015 №842, 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 15.05.2018 №366, 18.09.2018 № 886, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Акланган затларны җирләүгә чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Акланган затларны җирләү чыгымнарын каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында күрсәтелде.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):»;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 п.).»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Акланган затларны җирләүгә чыгымнарны кайтаруны билгеләү (алга таба – чыгымнарны кайтаруны билгеләү) | 6 статья 63-ТРЗ номерлы закон, |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 1.2 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Нигезләмәнең 1.2 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте | Чыгымнарны каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү чыгымнарны каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | Нигезләмәнең 2.5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Җирләү чыгымнарын каплау турында гариза (почта адресын яисә гариза бирүче тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп), түбәндәгеләргә туры китерелгән, киңәш ителә торган формада:<br>Акланган затларны җирләү бурычын үз өстенә алган гражданнар өчен 1 нче кушымта;<br>Акланган затларны җирләү бурычын үз өстенә алган оешмалар өчен 2 нче кушымта.<br>2. Тотылган чыгымнар фактын раслый торган түләү документлары.<br>3. Аклану турында документ күчермәсе.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп | Нигезләмәнең 2.2, 2.3 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя. Гариза белән документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына: акланган затның вафатын дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында); хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында). Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган | 143-ФЗ номерлы федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 | |

| | | |
|---|---|---|
| | елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Вафат булган көннән соңгы алты ай узып киткәч дәүләт хезмәте күрсәтелү буенча мөрәҗәгать итү.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>3. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләргә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документларның (документларның күчермәләренең) тапшырылуы.<br>4. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу. | 8-ФЗ номерлы федераль законның 10 ст. 3 п. |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | билгеләнмәгән | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә | |

| | | |
|---|---|---|
| мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге; | 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән | инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Үзәк бүлегенә гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 11 пункты; 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$, $21^2$ статьялары; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Чыгымнарны каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) чыгымнарны кайтаруны билгеләү өчен теркәлгән документлар пакеты белән гаризаны кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны төзәтү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктта «хезмәткәр» сүзен «учреждение белгече» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Акланган затларны җирләүгә чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Акланган затларны җирләүгә чыгымнар каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелүен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында
БЕЛЕШМӘЛӘР

1.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

1.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган

затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.07.2015 №475, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 351, 27.11.2017 №835, 15.05.2018 №368, 18.09.2018 №883, 17.01.2019 №31, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652 боерыклары кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзенә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта «дәүләт хезмәте алучының даими яшәү урыны» сүзләрен «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәте аркасында килеп чыккан башка авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданның яшәү урыны» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында күрсәтелде.»;

1.4.2 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 п.).»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие (алга таба – пособие) билгеләү | ч.4. ст.14 Закона Российской Федерации 1244-1 номерлы законы; Кагыйдәләрнең 1 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Кагыйдәләрнең 2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә | |

| | | |
|---|---|---|
| каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | кадәр озайтыла.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Пособие билгеләү турында гариза (гариза бирүче тарафыннан кредит оешмасында ачылган почта адресын яисә счет реквизитларын күрсәтеп) (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән). Опекун (попечитель) гариза бирүчегә акча күчерү өчен югарыда күрсәтелгән кредит оешмасында опекун (попечитель) тарафыннан ачтырылган номинал счет реквизитларын күрсәтә.<br>2. Вафат булган затның социаль ярдәм чараларына хокук бирә торган таныклыгы күчермәсе.<br>3. Вафат булуны теркәгән вакытта гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан бирелә торган, билгеләнгән формалы вафат булу турында белешмә күчермәсе.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ һәм җирләү чыгымнарын раслаучы түләү документларын күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган | Кагыйдәләрнең 2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш. | |
| | Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гариза белән документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына: Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарның вафат булуын дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында); хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында). Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булған хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |

| | | |
|---|---|---|
| шул исәптән электрон формада | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: | 880 номерлы ТР МК карары белән |

| | | |
|---|---|---|
| һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы | Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>белгечләрнең Регламентны бозуына карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан | расланган Тәртипнең 2.4 пункты<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау | артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/) сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Үзәк бүлегенә гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль законда һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 63-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ ст., $21^2$ статьялары»; |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) пособие билгеләү буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны төзәтү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның дүртенче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктта «хезмәткәр» сүзен «учреждение белгече» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Чернобыль АЭСында һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында
БЕЛЕШМӘЛӘР

1.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»
дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

1.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |